ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

27 май, 2021 ел № 7/9

Инициатив проектлар өлешендә Шәһәр Советының аерым Карарларына үзгәрешләр кертү турында

««Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 20 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль закон, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәрендә территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру Тәртибен раслау турында» 2014 елның 17 апрелендәге 30/18 номерлы Карары белән расланган (Шәһәр Советының 2014 елның 10 июлендәге 31/9 номерлы Карары редакциясендә) Яр Чаллы шәһәрендә территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 2 статьяга түбәндәге эчтәлекле 6 өлеш өстәргә:

«6. Территориаль иҗтимагый үзидарә органнары инициатив проектны проект инициаторлары сыйфатында тәкъдим итә алалар.»;

2) 8 статьяның 16 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 10 пункт өстәргә:

«10) инициатив проект турында фикер алышу һәм аны хуплау мәсьәләсе буенча карар кабул итү.».

2. Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәрендә гражданнарны сораштыру турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2007 елның 17 маендагы 22/8 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәрендә гражданнарны сораштыру турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 4 пунктта түбәндәге эчтәлекле 3 пунктча өстәргә:

«3) инициатив проектка теләктәшлек итү турында гражданнарның фикерен ачыклау мәсьәләләре;»;

2) 6 пунктта түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Гражданнарның инициатив проектка ярдәм итү турындагы фикерен ачыклау мәсьәләсе буенча үткәрелгән сораштыруда уналты яшькә җиткән муниципаль берәмлек халкы катнашырга хокуклы.»;

3) 14 пунктны түбәндәге эчтәлекле 3 пунктча белән тулыландырырга:

«3) Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче уналты яшькә җиткән кешеләр (инициатив проектка теләктәшлек итү турында фикерне ачыклау мәсьәләләре буенча).»;

4) 15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Гражданнарны сораштыру билгеләү турындагы карар муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан кабул ителә. Гражданнар арасында сораштыру үткәрү өчен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге шәһәрнең рәсми сайты кулланыла ала.

Гражданнар арасында сораштыру үткәрү турында Шәһәр Советы карарында билгеләнә:

1) сораштыру үткәрү датасы һәм сроклары;

2) сораштыру уздырганда тәкъдим ителә торган мәсьәләнең (мәсьәләләрнең) формулировкасы;

3) сораштыру үткәрү методикасы;

4) сораштыру кәгазе формасы;

5) сораштыруда катнашучы шәһәр халкының минималь саны;

6) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтыннан файдаланып гражданнар арасында сораштыру уздырган очракта, сораштыруда катнашучыларны идентификацияләү тәртибе.»;

5) 33 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«33. Сораштыруда катнашучылар исемлегенә сораштыру үткәрү күздә тотылган территория чикләрендә даими яки нигездә  яшәүче гражданнар кертелә. Исемлектә сораштыруда катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы һәм яшәү урыны күрсәтелә.»;

6) 63 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1)  Яр Чаллы шәһәре бюджеты средстволары хисабына - Яр Чаллы шәһәре Хакиме, Шәһәр Советы яисә шәһәр халкы инициативасы буенча сораштыру үткәргәндә;».

3. Шәһәр Советының «Гражданнар җыелышлары һәм конференцияләре турында Нигезләмәне раслау хакында» 2007 елның 4 октябрендәге 25/20 номерлы Карары белән расланган гражданнар җыелышлары һәм конференцияләре турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 2 пунктның беренче һәм икенче абзацларында «җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары» сүзләреннән соң «инициатив проектларны кертү һәм аларны карау, муниципаль берәмлек территориясендә территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча фикер алышулар буенча гражданнар җыелышлары үткәрелергә мөмкин.» сүзләрен өстәргә;

2) түбәндәге эчтәлектәге 2.1 пункт өстәргә:

«2.1. Инициатив проектларны кертү һәм аларны карау мәсьәләләре буенча гражданнар җыелышында уналты яшькә җиткән һәм тиешле территориядә яшәүчеләр катнашырга хокуклы. Инициатив проектларны кертү мәсьәләләрен карау һәм тикшерү максатларында гражданнар җыелышын билгеләү һәм үткәрү тәртибе Шәһәр Советы Карары белән билгеләнә.».

4. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф. Ш.Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев